БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» 05 2026 ел № 181

**Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Балтач районы бүлеге хезмәткәрләрен Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты буйсынуындагы спорт объектларына керү өчен түләүдән азат итү турында**

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Балтач районы бүлегенең мөрәҗәгатен карап, эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең физик әзерлеген арттыру, оператив-хезмәт бурычларын үтәүгә әзерлекне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Балтач районы бүлеге хезмәткәрләренә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты буйсынуындагы спорт объектларына бушлай керүне тәэмин итәргә.

2. Спорт объектларына керү шартларын түбәндәгечә билгеләргә:

2.1. Хезмәткәрнең хезмәт таныклыгы булу;

2.2. Тренировкалар графигын алдан килештерү;

2.3. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Балтач районы бүлеге җитәкчелеге тарафыннан исемлек төзү.

2.4. Объектларның эчке тәртип кагыйдәләрен үтәү.

3. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты буйсынуындагы муниципаль учреждение җитәкчеләренә Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Балтач районы бүлеге хезмәткәрләренең массакүләм йөрү өчен билгеләнгән сәгатьләрдә спорт объектларына түләүсез нигездә, тоткарлыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов